ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11 декабрь, 2018 ел № 28/11

Шәһәр Советының 2013 елның 30 маендагы «Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, суны читкә агызып җибәрү, коммуналь комплекс оешмалары тарифларын, өстәлмәләрен көйләү өлкәсендә вәкаләтләрне башкару Тәртибен раслау турында» 25/12 санлы Карарын гамәлдән чыккан дип тану хакында

2014 елның 29 декабрендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында Федераль закон»га, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану турында» 458-ФЗ санлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2013 елның 30 маендагы «Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, суны читкә агызып җибәрү, коммуналь комплекс оешмалары тарифларын, өстәлмәләрен көйләү өлкәсендә вәкаләтләрне башкару Тәртибен раслау турында» 25/12 санлы Карарын гамәлдән чыккан дип танырга, «Шәһри Чаллы» газетасының 2013 ел 14 июньдәге 45 санында, 19 июньдәге 46 санында басылган.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев